| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

***Постановление*** ***Карар***

**12.02.2020** **Чистай шәһәре** **№ 66**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 ноябрендәге «Эчке муниципаль финанс контроле һәм эчке финанс аудиты буенча бюджет акчаларының Баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны анализлау Тәртибен раслау турында»гы 961 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 ноябрендәге «Эчке муниципаль финанс контроле һәм эчке финанс аудиты буенча бюджет акчаларының Баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны анализлау Тәртибен раслау турында» 961 номерлы карарына Чистай шәһәр прокурорының 2020 елның 07 февралендәге 02-08-02-2020 номерлы протестын карап тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын «Россия Федерациясе Бюджет кодексына дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 июлендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләргә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 ноябрендәге «Эчке муниципаль финанс контроле һәм эчке финанс аудиты буенча бюджет акчаларының Баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны анализлау Тәртибен раслау турында»гы 961 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль

районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга (http://chistopol.tatarstan.ru/).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Л.Х. Кашаповага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р.Хәсәнов